Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№3 (96)

13 февраль 2014 ел


# Бәхетне белемдә эзләгез!

Белем иленә яңа сәяхәт башланды, дусларыбыз. 2013/2014 уку елының икенче яртыеллыгына да кердек. Ул да алдагылары кебек тиз генә узып китәр, зачет-имтихан тапшырыр вакытлар җитәр. Дипломлы белгеч булганыгызны да сизми калырсыз. Шуңа күрә уку йортыбызда узган һәр көннең кадерен белегез. Белем туплау, яхшы тәрбия алу, талантларны ачу, максатларны тормышка ашыру өчен тудырылган шартлардан дөрес файдаланыгыз. Студентлык чоры ул – киләчәккә юл салу дигән сүз!



«Лица КФУ» проекты фотосы

## Вакыйгалар эзеннән

Күптән түгел профориентацион эш кысаларында **КФУ**ның **ПЕДАГОГИКА ПРОФИЛЕ БУЕНЧА КАФЕДРАЛАР** һәм **БҮЛЕК УКЫТУЧЫЛАРЫ САБА РАЙОНЫНДА БУЛЫП КАЙТТЫ**. Анда, Казан университеты мөгаллимнәре белән очрашырга дип, районның 500дән артык иң яхшы чыгарылыш сыйныф укучылары җыелган иде.

• • • •

**8 ФЕВРАЛЬ** көнне Казан университеты ректоры **И.ГАФУРОВ ФИЗИКА ИНСТИТУТЫ ҖИТӘКЧЕЛЕГЕ БЕЛӘН ОЧРАШТЫ**. Чара барышында институт директоры **А.АГАНОВ** 2013 елда эшләнгән эшләргә нәтиҗә ясады һәм 2014 елга планнары һәм куелган максатлар турында сөйләде. Очрашуда университет проректорлары, кафедра җитәкчеләре һәм күренекле галимнәр катнашты. Ректор коллективның эшмәкәрлек юнәлешенең асылына аерым игътибар итәргә киңәш бирде. Шулай ук яшьләргә фәнни яктан үзебездә үсәргә мөмкинлек бирергә кушты.

• • • •

**10 ФЕВРАЛЬ** көнне шундый ук **ЧАРА ЭКОЛОГИЯ** һәм **ГЕОГРАФИЯ ИНСТИТУТЫНДА БУЛДЫ**. Биредә шулай ук ректор **И.ГАФУРОВ**, икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор **М.САФИУЛЛИН**, фәнни эшчәнлек буенча проректор **Д.НУРГАЛИЕВЛАР** катнашты. Очрашуга йомгак ясап, ректор иң әһәмиятле юнәлешләрне билгеләргә һәм алар өстендә эшләргә керәклеген әйтте.

• • • •

Шушы көннәрдә Краснодар краенда **«БӨТЕНРОССИЯ СТУДЕНТЛАР МАРАФОНЫ»** узды. Россиянең биш федераль округы югары уку йортларыннан 400дән артык катнашучылар арасында Казан федераль университеты командасы да бар иде. Бәйге нәтиҗәләре буенча, «Казан» командасы спорт өлкәсендә 3 нче урын, иҗади конкурста 2 нче урын һәм гомумкоманда марафонында 2 нче урынга лаек дип табылды. Студентларыбызны җиңүләре белән тәбрик итәбез!

• • • •

**КФУ**ның **АЛАБУГА ИНСТИТУТЫ** һәм М.В.Ломоносов ис. **МДУ**ның **ХАЛЫКАРА БЕЛЕМ БИРҮ ҮЗӘГЕ АРАСЫНДА КИЛЕШҮ ТӨЗЕЛДЕ**. Аның нигезендә бик тиздән Алабуга институты базасында рус телен өйрәнү һәм чит ил вәкилләренә рус теле буенча дәүләт тестын уздыру үзәге булдырылачак.

• • • •

«Пятница! Челны» телеканалында «Твоё. Моё. Наше!» исемле **ЯҢА ЯШЬЛӘР ПРОГРАММАСЫ ЭШЛИ БАШЛАЯЧАК**. Иҗади яшьләрне туплау мәсьәләсен журналист, пиарщик һәм реклама белгечләрен әзерли торган Яр Чаллы институтының гаммәви коммуникация кафедрасы үз өстенә алган. Әлеге кафедра студентлары беренче пилот тапшыруын эшләделәр. Ул 12 февраль көнне эфирга чыкты.

• • • •

**11 ФЕВРАЛЬ** көнне Казан федераль университетында чираттагы дисциплинаара **РЕКТОР СЕМИНАРЫ УЗДЫ**. Бу юлы ул магнитлы резонанс һәм аның гамәли кушымталарының актуаль мәсьәләләренә багышланган иде. Утырышта фәнни эшчәнлек буенча проректор Д.Нургалиев, галимнәр, аспирантлар һәм студентлар катнашты. Чарада алты доклад белән чыгыш ясадылар. Һәр чыгыштан соң, катнашучылар темага бәйле әңгәмә кордылар. Киләсе ректор семинары 14 февраль көнне булачак. Ул «Новые технологии разработки высоковязких нефтей и природных битумов» темасына багышланачак.

• • • •

**12 ФЕВРАЛЬДӘ КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНА** Россия Федерациясенең Тышкы эшләр министрлыгы вәкилләреннән торган **ДЕЛЕГАЦИЯ КИЛДЕ**. Алар университет җитәкчелеге белән очрашты.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды*

• Юбиляр

# Ике күңелле Кеше!

Динара МИННЕКАЕВА

«Мәхәббәт төрле булырга мөмкин. Әти-әнине бер төрле, туган илне икенче төрле, тормыш иптәшен, балаларны, дусларны башкача яратасың. Ләкин эшне гади генә яратып булмый икән! Мин эшемә бөтен күңелемне бирәм!» – ди педагогика фәннәре докторы, профессор Резеда Мөхәммәтшина.



Резеда – чәчәк, дигәнне аңлата. Аңа бу исемне әтисе И.Юзеевның «Резидәкәй» пьесасы хөрмәтенә куша. Резеда шулай ук шифа, кешегә дару мәгънәсен дә аңлата. Резеда Фаил кызы Мөхәммәтшина да бик яхшы табиб булган булыр иде. Ләкин аның бу хезмәте дә бик изге. Ул яшьләргә белем бирә, аларны сүз белән тәрбияли. Чын Кеше булырга өйрәтә.

Резеда ханым кечкенәдән укытучы булырга хыяллана. Гаиләдә салынган ныклы нигез аңа киләчәктә зур үрләр яуларга ярдәм итә. Кечкенәдән үк әдәби китап-журналлар укып, театрларга йөреп үскән Казан кызы Резеда ханым җәйге ял вакытларында әтисе ягыннан туганнары янына – Арчага кайтып йөри. Шуңа күрә арчалылар аны якын итеп: «үзебезнеке» дип йөриләр икән. Тормышының бу вакытларын бик сагынып искә ала ул: «Авылдагы дус кызларым белән татарча сөйләшеп, җырлап ята идек. Аннары икенче җәйгә кадәр хатлар алыша идек. Шулай итеп мин туган телемне бик камил дәрәҗәдә белә идем. Әти-әниемә милли тәрбия биргәннәре өчен бик рәхмәтле. Немец шагыйре Гете: «Ана телен белмәгән кеше шәхес була алмый», – дигән. Бу сүзләр бик дөрес.

Туган теле белән бергә, рус телен, әдәбиятына да гашыйк була Резеда ханым. Укытучысы Римма Михайловнага охшарга тели. Хыялын тормышка ашыру максатыннан, педагогика институтының чиста рус бүлегенә укырга керә. Зачет кенәгәсендә бер генә «4»ле билгесе дә булмаган студент кыз факультетта комсорг вазифасын башкара. «Икенче курстан комсомол оешмасының ирекле сәркатибе булып, тулы ставкада эшли башладым. Бу эш миңа бик зур тәҗрибә бирде. Һәр җитәкчене комсомол аша үткәрер идем, ул үзең өчен генә түгел, башкалар өчен дә җаваплы дигән сүз. Ә безнең факультет бик зур иде. Анда тарихчылар да, рус һәм татар филологлары да әзерләнә иде. Алар төрле, һәркайсына аерым игътибар кирәк. Без бер елгы булсак та, бер курста укысак та, миңа хөрмәт итеп, «Резеда апа», дип эндәшәләр иде», – дип сөйли.

Институтны уңышлы тәмамлап, Резеда ханым Казанның икенче педагогика көллиятендә рус теле һәм әдәбиятын укыта башлый. Бирегә эшкә алынуын ул зур галим, рәссам, оратор, искиткеч шәхес Татьяна Геллер белән бәйли. Институтта укыган чорда Резеда ханым эстетика түгәрәгенә йөри. Ничек итеп кино, спектакль карарга, картиналарга сокланырга, бер сүз белән әйткәндә, матурлыкны күрергә өйрәнә. Студентлар остазлары Татьяна Геллер биргән темалар буенча лекцияләр язып, бөтен Казан, Татарстан буенча йөриләр, тәҗрибә туплыйлар. «Т.Геллерның укучысы дигәч, мине көллияткә ике куллап алдылар», – ди ул. Эшкә урнашу белән, 28 сәгать дәрес бирәләр, утыз кыз һәм бер малайдан торган төркемгә академик җитәкче итеп билгеләр. Монда да Резеда ханым үзен яхшы укытучы, оештыручы буларак күрсәтә. Студентларын Россиянең төрле шәһәрләренә экскурсияләргә алып бара, мәдәни-агарту чараларына әзерли, үзлектән башлангыч сыйныфларны укыту методикасын өйрәнә, һәр укучысының яшәү шартлары, гаиләсе белән танышып чыга.

Укыту эшенә дә зур җаваплылык белән карый. Һәр иншаны җентекләп тикшерә, язучы-шагыйрьләр иҗатын ныклап өйрәнә. Шуның өстенә гаилә, балалар, өйдәге эшләрне дә карарга вакыт таба.

Ә тормышка Резеда ханым зур мәхәббәт белән сыйныфташына чыга. Алар бер кыз һәм ул тәрбияләп үстерәләр. Кызлары Альбина безгә зәңгәр экраннар аша яхшы таныш. Бүгенге көндә ул «Бала-СИТИ» балалар бакчасы җитәкчесе. 4 яшьлек Аяз – Резеда ханымның яраткан оныгы. Уллары Булат КФУның Икътисад һәм финанслар институтында белем ала. «Көллияттә эшләгән вакытта, яшь ярымлык кызыбыз Альбина белән әтием утырды. Ә мин эштән шыпырт кына кайтып керә идем дә, аерым бер бүлмәгә бикләнеп, дәрескә әзерләнә идем. Альбинаны анда кертмиләр иде, монда бүре яши, дип әйтәләр иде. Ә ул, ишек астыннан карап, «әнием», дип елап ята иде. Мин дә күз яшьләре агыза-агыза дәфтәрләр тикшерә идем. Ничек кенә авыр булса да, эшемне, студентларымны ярата идем», – дип сөйли Резеда ханым.

Эшкә мәхәббәте педагогика институтына күчкәч тагын да көчәя. Монда да аны Татьяна Геллер үзе чакыра. Көллияте белән аерылуны Резеда ханым бик авыр кичерә, ләкин тормышның четерекле мизгелләрендә һәрвакыт ярдәмгә кулы сузган әнисе аңа бу юлы да бик дөрес киңәшләр бирә. Укучылары белән табып бетермәгән якынлыкны ул студентлар активы белән аралашып таба. Алга таба кафедра җитәкчесе, декан вазифаларын башкара, ике ел педагогика һәм психология институты директоры булып тора. Хәзерге көндә Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Л.Н.Толстой ис. Рус һәм чит ил филологиясе бүлеге җитәкчесе. «Укытучы, беренче чиратта, балаларны яратырга тиеш, аннары гына фәнен. Мин дә укучыларымны балаларны яратырга өйрәтергә тырышам», – ди галим. Резеда ханым – бик гади җитәкче. Һәркемне якын итә, хәленә керә белә, ярдәм итә. Әле һаман да белемен арттыру белән шөгыльләнә: инглиз телен өйрәнә.

Резеда ханым фәнен дә бик ярата. Рус символизмы поэзиясенә багышланган кандидатлык диссертациясен Мәскәүдә яклый. Докторлык диссертациясе мәдәниятләр диалогына – рус – татар, төрек – славян, мөселман – христиан – багышланган. «Тема бик авыр иде, ләкин мин аны ачып бирә алдым. Ике телне, ике динне, ике мәдәниятне белүем зур ярдәм итте. Кеше ике телле, ике мәдәниятле булырга мөмкин. Ә мин биментальлек дигән гипотеза чыгардым. Психологлар минем белән килешми, ике күңел була алмый, дип каршы киләләр. Менә мин ике күңелле кеше! Миңа икесе дә якын! Миңа хәтта Раиф тыюлыгындагы 95яшьлек Филарет атакайның, теманы син түгел, ә ул сине күктән үзе сайлаган, дигәне бар».

Минемчә, Резеда ханымның күңеле икәү генә дә түгел! Ул шулкадәр зур, шулкадәр киң!!! Анда күпме мәхәббәт, күпме наз сыйган! Салкын, карлы көндә туса да, аның күңеле кояш кебек балкый. Бу бер яклы мәхәббәт кенә түгел, ә чын мәгънәсендә, туган иленә, туган нигезенә, теленә, мәдәниятенә, әти-әнисенә, балаларына, оныкларына, укучылары-студентларына, остазлары-хезмәттәшләренә, эшенә карата зур СӨЮ! Җавап таләп итми торган Сөю!

***P.S.** Күптән түгел Резеда Мөхәммәтшина үзенең күркәм юбилеен билгеләп үтте. Соң булса да, аны редакциябез исеменнән котлап, бәхетле озын гомер, эшендә зур уңышлар телибез.*

• Гомер фасыллары

# 100 яшьлек «Красавица»!

Алинә САДЫЙКОВА

100 яшькә кадәр яшәргә күпләр хыялланадыр. Кемнәрдер бу хыялны тормышка ашыру бәхетенә ия. Андый кешеләр бармак белән генә санарлык булса да, алар бар! Казан федераль университеты да үзенең 100 яшьлек хезмәткәрләрен зурлый!



Влад Михневский фотосы

Фәрзәнә Мифтах кызы Шиһапова 1914 елның 1 февралендә туа. Ул гомеренең 10 елын Казан педагогика институтына багышлаган. Фәрзәнә апа уку йортындагы тәртип, чисталык һәм пөхтәлек өчен җавап биргән, укытучы һәм студентларга уңайлы эш һәм уку шартларын тудыру өчен тырышкан. Аларның җылы рәхмәт сүзләре, туганнарының, якыннарының яратуы нәтиҗәсендәме, Фәрзәнә апа быел күркәм юбилеен – 100 яшьлеген каршылады.

Бөтен кешегә дә татып карарга насыйп булмаган мондый үзенчәлекле вакыйгадан университетыбыз да читтә калмады – юбилярны олы бәйрәме белән тәбрикләргә дип, уку йортыбыз җитәкчелеге Фәрзәнә апаларга юл тотты. Хуҗалык эшләре буенча проректор **Ленар Сафиуллин** (*фотода*), 1 нче хуҗалык бүлеге җитәкчесе, хуҗалык эшчәнлеге идарәсенең профбюро рәисе **Әхмәт Агишев**, хуҗалык эшчәнлеге идарәсе җитәкчесе **Сәүбән Әхтәмовлар** университетыбызның олы хезмәткәрен тәбрикләргә, тиешле бәя бирергә һәм хөрмәт белдерергә алындылар.

Фәрзәнә апаны котларга теләүчеләр исемлегендә университет кына булмаган икән: шәһәр администрациясе, дуслары, туганнары, якыннары. Безне кочак-кочак чәчәк бәйләмнәре тотып, елмаеп утырган чын татар әбисе каршы алды. Университет тарафыннан яңгыраган тәбрикләү сүзләренә матур итеп җавап кайтарды ул: «Сез бик матур кунаклар! Сезгә ни әйтсәм дә, аз булырдыр кебек тоела. Мине искә алып, ихтирам итеп килгәнегез өчен зур рәхмәт сезгә!» Яше хәйран булса да, юбилярның кәефе яхшы, тавышы нык, күңеле хөр иде. Бераз вакыттан соң, Фәрзәнә апа хатирәләргә бирелеп алды. Аның тормыш юлы бер дә җиңелләрдән булмаган: бик яшьли әти-әнисеннән калган кыз кечкенәдән үк үз көнен үзе күрергә күнеккән. Аңа Ерак Көнчыгышта яшәргә туры килгән, Бөек Ватан сугышы дигән афәтнең ни икәнен яхшы аңлый. Фарзәна апа солдатларга бияләйләр тегә торган булган. «Солдатлар шуның өчен мине бик яраталар иде, «Красавица» дип йөртәләр иде», – дип елмаеп искә алды ул.

Фәрзәнә апаның улы Илдус Шәрипович та университет делегациясенә зур рәхмәтләрен җиткерде: «Онытмаганыгыз, хөрмәт итеп, зурлап килүегез өчен рәхмәт. Шуны әйтәсем килә: университет үзенең хезмәткәрләренә, аеруча олы яшьтәге кешеләргә, һәрвакыт игътибарлы, җылы мөнәсәбәттә булды. Менә мин гомер буе заводта инженер булып эшләдем. Мине бер тапкыр да эшемнән котлаганнары юк. Ә әнине ел саен искә аласыз! Безне зурлаганыгыз өчен, Аллаһы Тәгалә сезне дә зурласын!» Ул Әхмәт Агишевка әлеге очрашуны оештырганы өчен аерым рәхмәтләрен җиткерде.

Бу көнне Фәрзәнә апаның бусагасыннан кеше өзелмәде, чәчәк бәйләмнәре килеп, җылы тәбрикләү сүзләре явып торды. Якыннарыгызның, оныкларыгызның мәхәббәтен сизеп, аларга иптәш һәм терәк булып, әле тагын да яшәргә язсын Сезгә, Фәрзәнә апа!

• Эшлекле сөйләшү

# «Эшебезнең исеме җисеменә туры килә»



Әңгәмәдәш **Динара МИННЕКАЕВА**

Узган ел көченә кергән мәгариф турындагы законнар, илебездә башланып киткән Мәдәният елы турында күренекле җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе, Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Исмәгыйль улы Вәлиев белән сөйләштек.

**– Разил Исмәгыйлевич, газета укучыларыбызны Сез җитәкли торган комитет эшчәнлеге, аның максат һәм бурычлары белән якыннанрак таныштырсагыз иде?**

- Безнең комитет турында сораганда, мин һәрвакыт «аның исеме җисеменә туры килә», дип җавап бирәм. Ул «Татарстан Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты» дип атала. Димәк, шушы исемдәге мәсьәләләр аның төп эшчәнлеген чагылдыра. Шулай да безнең даирә тагын да киңрәк, без бу проблемалар белән генә чикләнеп калмыйбыз, дини оешмалар белән дә тыгыз элемтәдә торабыз. Дингә кагылышлы закон проектлары, карарлар безнең тарафтан әзерләнә. Аннан соң матбугат: газеталар, журналлар, радио, телевидение, нәшриятлар да безнең комитет карамагында. Иҗтимагый оешмаларның эшчәнлеге дә безнең игътибар үзәгендә.

**- Ә Комитет үзенең эшчәнлеген кайчан башлап җибәрде?**

- 1990 елда, Дәүләт суверенлыгы турында Декларация кабул ителгәч, яңа законнар карала башлады. Шуннан соң безнең комитет исемен 3 тапкыр үзгәртте. Туксанынчы еллар башында Милли мәсьәләләр һәм мәдәният буенча даими комиссиясе дип аталдык. Димәк, ул чорда милли мәсьәләләр беренче урында торган. Законда кайсы сүз алга куела, шул мөһимрәк санала. Биш ел узганнан соң, аның исеме тагын алышынды. Ул вакытта Фәннәр академиясе оешкан иде, фәнгә игътибар артты. «Татарстан Дәүләт Советының Фән, мәгариф, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты» дип аталдык. Аннары, 5 ел узганнан соң, мәгариф өлкәсендә реформалар башланды, мәгариф беренче урынга чыкты.

> Әгәр дә кеше үз алдына студент вакытта ук бер олы максат куймый икән, ул кешедән беркайчан да шәхес чыкмый. Моның өчен беренче чиратта сәләтеңне чамаларга һәм нәрсә теләгәнеңне ачыкларга кирәк. Аннары инде бөтен нәрсә: укыган китапларың, караган киноларың, спектакльләрең, аралашкан кешеләрең менә шушы максатыңа хезмәт итәргә тиеш.

Комитетның исемнәре алышынуга карап, безнең республикада кайсы өлкәнең кайчан приоритетлы булуын чамаларга мөмкин.

**- Ә мәгариф өлкәсендәге проблемалар,үзгәрешләр нидән гыйбарәт иде?**

- Соңгы елларда мәгариф өлкәсендә бик күп реформалар булды. Үткән елдагы зур вакыйгаларыбызның берсе - Россиянең мәгариф турындагы яңа законы кабул ителде. Заман үзгәрде, таләпләр үзгәрде, алар яңа законда чагылыш табарга тиеш иде. Россиянең мәгариф турындагы закон поектын башта Россиянең мәгариф һәм фән министрлыгы сайтына элеп куйдылар һәм халыктан фикерләр сорадылар. Җәмәгатьчелектән 20 меңнән артык тәкъдим килде. Без дә, Татарстан законын әзерләгәндә, шулай ук эшләдек, халыктан бик күп тәкъдимнәр алдык һәм аларның шактыен файдаландык. Ниһаять, бу законнар кабул ителеп, 2013 елның 1 сентябреннән көченә керде.

**- Безнең республика тарафыннан әйтелгән тәкъдимнәр кабул ителдеме?**

- Яңа федераль законда югары уку йортларына кагылышлы аерым бер маддә барлыкка килде. Монда Татарстан Дәүләт Советының, шул исәптән безнең комитетның да өлеше зур. Моңа кадәр мәгариф законы буенча Россия субъектлары үзләренең югары уку йортларын ача алмыйлар иде. Татарстанның да үз югары уку йорты юк. Муниципаль институтлар бар билгеле, әйтик, Әлмәттә, Чаллыда, Түбән Камада. Без җибәргән 17 тәкъдим арасында «Россиянең субъектлары, республикалары үзләренең югары уку йортларын ача ала» дигән төзәтмә дә бар иде. Россия Федерациясе Федераль Җыелышының Дәүләт Думасында безнең тәкъдим үтте. Андый маддә хәзер федераль законда бар, без аны үзебезнең законга да керттек. Киләчәктә үзебездә югары уку йорты булдырырга теләсәк, аңа законнар мөмкинлек бирә.

**- Татарстанның үз университеты ачылыр дип уйлыйсызмы?**

- Татарстан ныклап аягына баскач, һичшиксез, аның үз мөстәкыйль университеты булырга тиеш дип саныйм. Чөнки федераль университетлар никадәр көчле, мөмкинлекләре никадәр зур булса да, аерым бер төбәкнең, республиканың мәнфәгатьләрен канәгатьләндереп бетерә алмыйлар. Аларның бурычлары башка. Алар бөтен Россиягә эшләргә тиеш, аларның масштаблары зур. Ә безгә инде, беренче чиратта, халкыбыз һәм республикабыз мәнфәгатьләрен кайгырткан бер гуманитар университет булдыру зарур. Бәлки, киләчәктә шундый уку йорты ачылыр да. Аның бик зур булуы мөһим түгел. Ул безгә милли кадрлар тәрбияләргә тиеш. Татарстан өчен генә түгел, ә татарлар яши торган бөтен төбәкләр өчен. Бу хакта без, депутатлар гына түгел, җәмәгатьчелек тә фикерен җиткереп тора. Димәк, мондый ихтыяҗ бар.

**- 2014 ел Россиядә һәм Татарстанда Мәдәният елы дип игълан ителде. Мәдәният өлкәсендә быел алга китеш булыр дип саныйсызмы?**

- Бу без бик тә көтеп алган карар иде, чөнки соңгы елларда төп игътибар мәгариф өлкәсенә булды. Укытучыларның хезмәт хакы күтәрелде. Мәктәпләрнең матди нигезен ныгыту,аларны ремонтлау, җиһазландыру буенча бик күп эшләр эшләнде. Балалар бакчалары төзү буенча да эшләр шактый активлашып китте. Тагын берничә елдан бакчаларга чират бөтенләй бетәр дигән өметтә торабыз. Мәдәният өлкәсендә мондый ук зур уңышларыбыз бар дип санамас идем. Дөрес, анда да алга китешләр булды. Яңа мәдәният йортлары салу буенча программа кабул ителде. Әмма бүгенге көндә әле шактый китапханәләребез авыр хәлдә. Кайберләрендә хәтта интернет та юк. Музейлардагы тарихи ядкарьләребезне саклау буенча тиешле җиһазлар булмавы да куркыныч тудыра. Бүгенге көндә мәдәният өлкәсендәге иң зур проблема – ул хезмәт хакы. Нинди генә мәдәният йортлары, китапханәләр, музейлар төзелмәсен, әгәр дә аларда эшләүче хезмәткәрләрнең хезмәт хакы мәгариф өлкәсендәгеләрнең яртысы кадәр генә икән, анда барырга атлыгып тормаячаклар.

**- Мәдәният елында нинди зур чаралар үткәрелер дип көтелә?**

- Мәдәният елын үткәрү буенча Хөкүмәт тарафыннан план төзелде, ул төрле вакыйгаларга бик бай булачак. Шуларның берсе һәм иң зурысы дияргә кирәк - Тюрксойның (төрки халыкларның мәдәниятләрен берләштерә торган оешма – *авт.*) Казан шәһәрен төрки халыкларының мәдәният башкаласы дип билгеләве. Узган ел шушы оешма Төркиянең Искешәһәр дигән шәһәрендә төрле чаралар үткәрде. Быел шушы максатта Казанның сайлануы мәдәниятебезнең югары дәрәҗәдә булуын күрсәтә. Без бит мөстәкыйль дәүләт түгел, андый чараларның Төркиядә, Казакъстанда, Әзәрбайҗанда, Кыргызстанда үткәрелүе табигый хәл. Димәк, Казан үзенең барлыгын дөньяга сиздерде, мондый зур чаралар үткәрергә сәләтле икәнен күрсәтте, дигән сүз бу. Универсиада үткәреп тә, Татарстан бөтен дөньяны шаккатырды. Мәдәният елына старт 25 мартта – мәдәният хезмәткләрләре көнендә биреләчәк. Тюрксойның беренче ачылыш тантанасы Тукай туган көндә - 26 апрельдә М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрында узачак..

**- Газетабызны укучы студентларга нинди теләк-тәкъдимнәр җиткерер идегез?**

- Мин заманына Казан университетында ике ел укыдым, аннары укуымны Мәскәүдә дәвам иттем. Ул чорларда без газеталарның бер генә санын да калдырмыйча укый идек. Сәбәпләре дә булгандыр, хәзерге кебек интернет юк иде бит. Студент булу –ул югары уку йортында уку гына түгел. Студент вакытта мин иң зур сабакны үзем белән бергә укыган иптәшләремнән алдым. Шул чорда мин олы дөньяга чыгуның сукмакларын таптым. Дөрес, беренче курс Казан белән танышып, яңа шартларга ияләшеп, ыгы-зыгы белән сизелмичә дә үтеп китте. Аннары әкренләп китап минем иң төп укытучыма, остазыма әверелде. Икенче курста инде ныклап китапханәгә йөри башладым. Укытучыларга да лекция укучы мөгаллим-галим дип кенә карарга ярамый, алар белән дустанә аралашырга өйрәнергә кирәк. Без ул елларда М.Мәһдиевләр, М.Госмановлар белән якыннан аралаштык һәм соңыннан алар безнең гомерлек өлкән дусларыбызга әверелде. Аларга без баштарак күктән төшкән кешеләргә караган шикелле карый идек, тора-бара якынайдык. Студентлар белән укытучылар арасындагы ара шулай әкренләп юкка чыгарга тиеш. Моның өчен, беренче чиратта, алар белгән кадәр белергә омтылырга кирәк. Алар да, үз чиратларында, студентларны үз ишләре санарга, якын күрергә тиешләр.

Мәскәүдән укып кайтып, шактый вакыт узгач, тормыш тәҗрибәсе туплагач, мине Татарстан Милли китапханәсенә директор итеп куйдылар. Ул чакта инде мин үземне шактый белемле санап йөри идем. Китапханәгә килдем, анда XIV гасырдан башлап, бүгенге көнгә кадәр нәшер ителгән 3 миллион ярым китап бар. Мин китап киштәләре арасына кердем дә шаккаттым, үземнең никадәр надан икәнемне аңлап, кәефем кырылды. Боларны ничек укып бетерим икән, дип, аптырашта калдым. Ул китапларны көне-төне укысаң да, 600-700 кеше гомере кирәк. Димәк, аларны беркайчан да укып бетереп булмый. Шулвакыт үземә максат куйдым: миңа кайсы китап кирәк, шуларны гына укыячакмын. Китап укыганда да, мәгълүмат туплаганда да, теләсә кая чәчелергә ярамый. Беренче чиратта, максатыңа ирешү өчен үзеңә нәрсә кирәк икәнне анык белү зарур.

• Чара

# Тугандаш халыклар җыены



■ Төрек тәрҗемәчесе, ТР Язучылар Берлеге әгъзасы Фатих Котлы

**Алинә БӘДРЕТДИНОВА,**
Алабуга институты

Алабуга институтында «Хәзерге тюркология: төрки халыкларның мәдәнияте, теле, әдәбияты һәм тарихы» дип аталган VII Халыкара тюркология конференциясе үтте.

Фән көнендә узган бу зур чара татар теле һәм чагыштырма филология факультетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы ярдәме белән оештырылды. Конференциянең максаты – татар теленең тарихын өйрәнү өлкәсендәге милли казанышларны үзләштерү, яңа лингвистик агымнар һәм грамматик өйрәтмәләр белән танышу һәм аларны төрки телләрне, аерым алганда татар телен тикшерүдә куллану. Чарага чит илләрдән һәм Россия төбәкләреннән күренекле галимнәр килде. Барлыгы 170тән артык доклад кабул ителгән. Конференция барышында 9 секция эшләде. Чыгышлар төрле һәм кызыклы булды. Пленар утырышта төрки телләрнең тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен өйрәнә торган төрле югары уку йортлары арасында фәнни үзәкләр бәйләнешен ныгыту; студентлар алмашын арттыру кебек мәсьәләләргә дә игътибар ителде.

Мондый конференцияләр укытучылар өчен, студентлар өчен бик файдалы һәм уңай фикерләр уята. Галимнәр белән танышу, аларның безнең эшләр белән кызыксынуларын күрү – алда тагын югары үрләр яуларга канатлар куя.

● Әдәби сәйләннәр



«МИН ҺӨРНӨРСӨНЕ ЙӨРӘК АША УЗДЫРА ТОРГАН КЕШЕ, ШУШЫ ХАЛӘТ ШИГЫРЬЛӘРДӘ ЧАГЫЛА», – ДИ ГАММӘВИ КОММУНИКАЦИЯ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ФӘННӘР ИНСТИТУТЫ СТУДЕНТЫ АЛСУ НУРГАТИНА. БҮГЕН БЕЗ СЕЗНЕН ИГЪТИБАРГА, ГАШЫЙКЛАР КӨНЕ УҢАЕННАН, ЯШЬ ШАГЫЙРӘНЕҢ ИҢ ТАТЛЫ ХИС – МӘХӘББӘТКӘ БАГЫШЛАНГАН ИҖАТ ҖИМЕШЛӘРЕН ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ.

## * * *

*Син*
*читләтеп киткән киләчәкне*
*Юата алмас керсез абыну,*
*Аннан калды бары сагыну...*

*Мин*
*калдырган хисләр җуелмаслар,*
*Һәрбер хистә безнең язмышлар,*
*тамчы-тамчы тама ялгышлар...*

*Без*
*югалткан вакыт безне юата,*
*Бергә булган минут хакына.*
*Хисләр берәм-берәм атыла...*

*Күзгеләргә кызсирпергә куркам,*
*Яшьле күңелемне күрермен...*
*Син кит минем хәтеремнән качып,*
*китә калсаң, күпне бирермен.*
*Ә син рәнҗет мине, син битәрлә,*
*Явыз сүзләр ташла тарафка.*
*Күзләремә җан ачуым тулар,*
*Күрә алмам сине, яратмам!*
*Туктап калган бүген синең белән*
*Киләчәктән үткән эзләрем.*
*Күзгеләрдән минем күзләр белән*
*карый миңа синең күзләрең...*

## Бәхет

*Күңелем тырнала*
*Уйларда сырлана –*
*Ахыргы тынгысыз бию.*
*Бизәлгән, таралган,*
*Ялкынга камалган*
*Тик сиңа кирәксез сөю.*

*Җиде ят җөмләнең*
*Җиде ят сүзләре -*
*Хилафи зәхмәтлек шаукымы.*
*Хисләрне өзгәләп,*
*Үзеңчә төзгәләп*
*Әйт миңа,*
*бәхетең арттымы?!...*

*Ышана алмадым*
*Бер хисең калмады?*
*Йөрәкне яндырып телгәндә.*
*Фәрештә сөргәне...*
*Уяныр идемме*
*Күзләрең төшләргә кергәндә?!*

*Оныттыр дисәм дә,*
*Ялварып йөрсәм дә,*
*Хакыйкать тәннәрен уята.*
*Син йолдыз күрәмсең,*
*Буйларым җитмәсен!!!*
*Бәхетле мин... Сине яратам!*

## Вокзал



*Бөтерелә, әйләнә җил,*
*Куып кар бөртекләрен.*
*Буран диләр кышның шулай*
*Җаны үксегән мәлен.*

*Күзләр күзгә, тешләр-тешкә*
*Шыкы-шыкы бәрелә.*
*Санаулы минутлар кала*
*Поездның китәренә.*

*Карашка караш бәрелә,*
*Күзнең ялларын тарап.*
*«Үпкәләмә. Аерылабыз.*
*Яратканыңны ярат...»*

*Бәс туңган керфекләреңә,*
*Күзләрең – бозлы элпә.*
*Җан эретерлек хисеңнең*
*Өметен өздем кичә.*

*Куллардан куллар аерыла,*
*Бу - шашыну. Бу - коткы.*
*Тешләргә кушыла поезд:*
*Шыкы-шыкы. Шыкы-шыкы.*

*Бәргәләнә буран булып,*
*Күңеле адашып калган.*
*...Ярату гына чын иде,*
*Калганы иде ялган.*

● Ачыш

# Хәрефсез китап?



**Гөлшат ГАЛӘВИЕВА,**
**Ләйсән ИСХАКОВА**

АРГЕНТИНА НӘШРИЯТЧЫЛАРЫ ДӨНЬЯДА МОҢА КАДӘР ТИҢЕ БУЛМАГАН, ШАККАТЫРГЫЧ КИТАП БАСТЫРГАН. ӘЛЕГЕ КИТАП УКЫРГА ЯРАТУЧЫЛАР ӨЧЕН ЗУР ЯҢАЛЫК БУЛЫП ТОРА.

Нәрсәсе белән гаҗәеп соң ул? Китап махсус пластик тышлыкка төрелгән. Баксаң, китаптан әлеге тышлыкны салдырып, беренче битен ачкан көннән башлап, аның битендәге язулар үзеннән-үзе әкренләп искерә, юкка чыга башлый икән. Моның сере гади: китапны бастырганда, нәшриятчылар махсус кара куллана, китапның тышлыгы да аерым химик состав белән эшкәртелә. Әлеге кара, кислород һәм кояш нурлары белән реакциягә кереп, ике ай эчендә бөтенләй күренмәс үк була. Мондый китап, озак вакыт киштәдә тузан җыеп, аны укыганнарын көтеп ята алмый. Шуңа да ул кешеләрне тизрәк һәм күбрәк укырга илһамландыра. Чөнки китапның 2 айдан соң укып булмаслыкка әйләнәчәген белеп тору – китап укуга үзе бер зур стимул. Кемнең акчасын җилгә очырасы килсен?!

КФУның Н.И.Лобачевский ис. милли китапханәсенең кульъязма һәм сирәк китаплар бүлеге җитәкчесе Эльмира Әмирханова Аргентинада басылган үзенчәлекле китаплар хакында үз фикерен җиткерде. Аныңча, төгәл фәннәр буенча бастырылган андый китапларның файдасы булмаячак. «Безнең КФУда мондый гаҗәеп китаплар чыгарсалар, студентларга бер яктан бик яхшы булыр иде. Юкса, кайбер студентлар дәреслек-китапларны имтихан алдыннан гына укый башлыйлар. Ә болай алар алданрак, 2 ай эчендә дәреслектәге мәгълүматны үзләштерерләр иде, чөнки имтихан вакытына китап битләре чип-чиста ак төстә калыр иде бит!»

Аргентина басма осталарының бу уйлап табуы безнең арага тиз генә кереп китмәс әле. Аргентинада ничектер, әмма без, татар китабы укучылар, китапларны кадерләп бүләк итәргә яратабыз, берберебездән алып укыйбыз, үзара фикер алышабыз. Минемчә, бу күренеш күпкә матуррак.



● Безнең канат

ТАТАР КЫЗЛАРЫ ЭЛЕК-ЭЛЕКТӘН ЧИБӘРЛЕКЛӘРЕ, ТЫЙНАКЛЫКЛАРЫ, УҢГАНЛЫКЛАРЫ БЕЛӘН ДАН ТОТКАННАР. МОНЫҢ ШУЛАЙ ИКӘНЛЕГЕНӘ КФУның Н.И.ЛОБАЧЕВСКИЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ЛИЦЕЕНДА БЕЛЕМ АЛУЧЫ 7-9 СЫЙНЫФ КЫЗЛАРЫ ТАГЫН БЕР КАТ ИНАНДЫРДЫ. ШУШЫ КӨННӘРДӘ БИРЕДӘ «ТАТАР КЫЗЫ» КОНКУРСЫ БУЛЫП УЗДЫ.



# Көн дә бәйрәм!

**Зилә ХАҖИПОВА, Наталья ПАНКРАТОВА**

Бәйгедә кызлар тамашачыларга үзләрен халкыбызның гүзәл затлары буларак тәкъдир иттеләр. Катнашучылар жюри әгъзалары хөкеменә иҗади чыгышларын тәкъдим итте. Кызлар татар халык җырларын башкардылар. Шулай ук татар композиторларының классик әсәрләре фортепиано, курайда уйналды. Кызлар өчен җан атарга дуслары, сыйныфташлары да килгән иде.

Нәтиҗәдә бәйгенең җиңүчесе дип 9 С сыйныф укучысы Әминә Гыйммранова танылды. 9 Д сыйныфы укучысы Айгөл Сибгатуллина – 2 урын иясе. 3 урынга 8 С сыйныфы укучысы Зилә Хаҗипова лаек булды. Башка кызларга төрле номинацияләрдә дипломнар тапшырылды. Әминә белән Айгөл шәһәр күләмендәге конкурска үттеләр. Соңрак Айгөл Сибгатуллина финалга чыкты. Аңа алга таба да уңышлар телибез! Барлык җиңүчеләрне тәбриклибез! Киләчәктә дә милләтебезнең гореф-гадәтләрен саклаучы, телебезне үстерүче чын ТАТАР КЫЗЛАРЫ булып калыгыз!

***

Безнең лицейда тормыш һәрчак гөрләп тора. Кышкы салкын көннәрнең берсендә уку йортыбызда күңелле, дәртле, искиткеч вакыйга – «Golden tangerine» («Алтын мандарин») инглиз җыры бәйгесе узды. Инде беренче тапкыр гына уздырылмый торган бу чара быел да укучылар, җитәкчелек һәм КФУның инглиз теле укытучылары игътибарын җәлеп итте. Соңгылары конкурсның дәрәҗәле хөкемдарлары булдылар.

Бәйгенең алып баручылары Артур Әүхәдиев һәм Алексей Васильев инглиз телен югары дәрәҗәдә белүләре белән таң калдырса, Любовь Фомичёва белән Александр Никаньшин тамашачыларны инглизчә башкарылган җырлары белән сокландырды. Ул көнне алардан кала да залда инглиз моңы, инглиз җыры гел яңгырап торды. Бер генә чыгыш та игътибарсыз калмады.

Җиңүчеләр рәтендә «Radioactive» җыры белән 8 С, «Pumped up kicks» җыры белән 10 Е сыйныфлары бар иде. Бәйгенең төп җиңүчесе дип 9 С сыйныфы укучысы Анна Хашова танылды. Конкурста җиңгән һәм аерым номинацияләрдә билгеләп үтелгән барлык катнашучыларны да котлыйбыз!

DARELFӨNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: А.Ю.Садыйкова
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317 оф.